**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 30 апрелендәге 1330 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 26 апрелендәге 1189 номерлы**
**«Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, бушлай файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.16 статьясына 2024 елның 28 декабрендәге 538-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм “Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм “Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы федераль законның 34 статьясындагы 7 өлешен гамәлдән чыккан дип тану хакында»гы федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон белән кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 26 апрелендәге 1189 номерлы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 1 апрелендәге 1242 номерлы, 2024 елның 14 маендагы 2005 номерлы, 2024 елның 30 сентябрендәге 4087 номерлы, 2025 елның 21 гыйнварындагы 71 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген, сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, бушлай файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 2.8.2.1 пунктның 13 пунктчасында «басылып чыгуы һәм» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**